КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 10 март г.Казань № 142

«Татарстан халыклары дуслыгы йорты» дәүләт учреждениесе тибын үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан халыклары Дуслыгы Йорты турында» 2005 ел, 6 декабрь, 567 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Татарстан халыклары дуслыгы йорты» дәүләт учреждениесе тибын «Татарстан халыклары Дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Учреждение) итеп үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Учреждениенең гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы гамәлгә ашыра дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына 60 көн эчендә Учреждениенең уставын расларга һәм аны дәүләт теркәвенә билгеләнгән тәртиптә алуны тәэмин итәргә.

4. Учреждениенең дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан халыклары дуслыгы йорты турында» 2005 ел, 6 декабрь, 567 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 28 декабрь, 753 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче һәм 3 нче пунктлар үз көчен югалткан дип санарга;

8 нче пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының иҗтимагый оешмалар белән һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегенә» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына» дигән сүзләргә алыштырырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин